# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11.11.2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024нче елның 11 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә, I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 1000 (бер мең) сум күләмендә һәм ЛНР һәм ДНРДА махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итеп үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

**1) торак пункт чикләрендәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын тоту, төзекләндерү һәм ремонтлау:**

– кыш айларында Иске Әлмәт авылы эчендәге Ленин урамы юлын карап тору өчен ,зияратка юлны кардан чистарту буенча төзелгән шартнамә буенча түләү;

- җәй айларында Иске Әлмәт авылы эчендәге Ленин урамы юлын карап тору өчен ,зияратка юлны кардан чистарту буенча төзелгән шартнамә буенча түләү;

- ком сибү юлы белән грейдерлау буенча шартнамә нигезендә Ленин урамын,зияратка юлны карау буенча түләү;

**2) традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү:**

- Иске Әлмәт авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу

**3) урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- урам яктырткычларын карап тоту, яктырткычлар алу;

**4) торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- үлән чаптыру;

**5) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү, ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;

- су җыю манарасын электр белән тәэмин иткән өчен түләү;

- суның сыйфатына анализ ясау;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 34 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны кертелгән кеше 21, бу 62 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен 21 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 2000,00 (ике мең) сум күләмендә үзара салым чараларын кертергә, моңа гражданнарның түбәндәге категорияләре керми: 1 һәм 2 группа инвалидлар, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасы студентлары өчен 1000,00 (бер мең) сум күләмендә , ЛХР һәм ДХРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарның үзара салымын түләүдән азат ителүе, шулай ук хатыны, балигъ булган балалары, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналары.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә:

**1) торак пункт чикләрендәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын тоту, төзекләндерү һәм ремонтлау:**

– кыш айларында Иске Әлмәт авылы эчендәге Ленин урамы юлын карап тору өчен ,зияратка юлны кардан чистарту буенча төзелгән шартнамә буенча түләү;

- җәй айларында Иске Әлмәт авылы эчендәге юлларны карап тору өчен ,зияратка юлны кардан чистарту буенча төзелгән шартнамә буенча түләү;

- ком сибү юлы белән грейдерлау буенча шартнамә нигезендә Ленин урамын,зияратка юлны карау буенча түләү;

**2) традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү:**

- Иске Әлмәт авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу

**3) рамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- урам яктырткычларын карап тоту, яктырткычлар алу;

**4) торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- үлән чаптыру;

**5) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү, ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;
- су җыю манарасын электр белән тәэмин иткән өчен түләү;
- суның сыйфатына анализ ясау;

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Әмәкәй авылы, и. Фәррахов урамы, 32 йорт һәм Мөслим муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына: http://muslumovo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы:** **И.И.Шакирҗанова**